**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 1** **02 ноябрь 2022 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Әсәй авыл җирлеге составына керүче
Әсәй авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 2 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:
« Сез, 2023 елда Әсәй авыл җирлеге Әсәй торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әсәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Әсәй авылы территорияләрен төзекләндерүне оештыру (дератизация, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агачларны кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Әсәй авылында бәйрәм һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар көне», авыл Спартакиадасында катнашучыларга бүләк һәм сувенирлар сатып алу);
- Әсәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Әсәй авылында энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү, килешү буенча эшләү өчен түләү;
- Әсәй авылы урамнарына вак таш һәм асфальт-бетон түшәлгән юлларны ремонтлау һәм карап тоту (сатып алу, ташу, вак таш җәю, билгеләр кую, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Әсәй авылында янгын сүндерү депосын тоту (электр энергиясе һәм җылылык өчен түләү, янгын инвентаре сатып алу).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 347 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 177 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 177 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге составына керүче Әсәй авылында узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: « Сез, 2023 елда Әсәй авыл җирлеге Әсәй торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әсәй авылында юлларны кардан чистарту;

- Әсәй авылы территорияләрен төзеклəндерүне оештыру (дератизация, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агачларны кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Әсәй авылында бәйрәм һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар көне», авыл Спартакиадасында катнашучыларга бүләк һәм сувенирлар сатып алу);

- Әсәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- Әсәй авылында энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү, килешү буенча эшләү өчен түләү;

- Әсәй авылы урамнарына вак таш һәм асфальт-бетон түшәлгән юлларны ремонтлау һәм карап тоту (сатып алу, ташу, вак таш җәю, билгеләр кую, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Әсәй авылында янгын сүндерү депосын тоту (электр энергиясе һәм җылылык өчен түләү, янгын инвентаре сатып алу).”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) һәм Әсәй авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әсәй авыл җирлеге Башлыгы Идрисов З.Ә.